**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ МОРДОВСКО-АФОНЬКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

423103, Мордовское Афонькино село, Цаплина ул., 19 дом

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**МОРДВА АФОНЬКӘСЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

423103, Мордва Афонькәсе авылы, Цаплин урамы, 19нчы йорт

тел. (84396) 3-48-29, факс: (84396) 3-48-49, email: Mord.Cmn2@tatar.ru

**№ 116** **18 декабрь 2023 ел**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы
Мордва Афонькәсе авыл җирлеге Советы

# КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Мордва Афонькәсе авыл җирлеге Советының 2012 елның 29 декабрендәге «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Мордва Афонькәсе авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» № 54 карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ, «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 4 августындагы № 438-ФЗ Федераль законнарга таянып Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Мордва Афонькәсе авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Мордва Афонькәсе авыл җирлеге Советының 2012 елның 29 декабрендәге «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Мордва Афонькәсе авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» № 54 карарына (Мордва Афонькәсе авыл җирлеге Советының 2018 елның 29 ноябрендәге №95; 2021 елның 19 августындагы №34; 2023 елның 19 маендагы № 67 карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 статьяның 24 абзацын яңа редакциядә бәян итәргә: «Россия Федерациясе Торак кодексының 15 статьясының 6 өлешендә күрсәтелгән билгеләргә туры килгән бина күп фатирлы йорт дип танылa».

1.2. 11 статьясының 3 пунктын түбәндәге эчтәлектәге 3_1 пункты белән тулыландырырга: «3_1) территориаль планлаштыру документларындагы торак пунктлар чикләренең урнашуы турындагы мәгълүматларның (шул исәптән торак пункт (торак пунктлар) чикләренең җир участоклары чикләре белән киселешен ачыклаган очракта) торак пунктларның чикләре турында мәгълүматларны Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрына керткәндә федераль закон нигезендә үзгәртелгән, Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрында булган күрсәтелгән чикләрнең урнашу урынын тасвирлауга туры килмәве;».

1.3. 12 статьясының 5 пунктын түбәндәге эчтәлектәге пунктча белән тулыландырырга: «капиталь төзелеш объектларының архитектура-шәһәр төзелеше кыяфәтенә таләпләр.».

1.4. 22 статьяның 2 пунктының 4 абзацын яңа редакциядә бәян итәргә: «җир участогында ярдәмче кулланыштагы төзелешләр һәм корылмалар төзү, аларга кертү критерийлары Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә;».

1.5. 42 статьясының 12 абзацын яңа редакциядә бәян итәргә: «Автомобиль юлына бүлеп бирү полосасының чикләре территорияне планлаштыру буенча документлар нигезендә билгеләнә, җир законнарында каралган очраклардан тыш».»

1.6. 42 статьясындагы 27 абзацны яңа редакциядә бәян итәргә: «юл сервисы объектларын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, аларны эксплуатацияләү, реклама конструкцияләрен сервитут шартларында урнаштыру һәм эксплуатацияләү максатларында автомобиль юлларына бүлеп бирелгән полосалар чикләрендәге җир кишәрлекләрен (шәхси автомобиль юлларыннан тыш) куллану, җир кишәрлекләрен инженер коммуникацияләрен сузу, күчерү, үзгәртеп кору, аларны сервитут шартларында эксплуатацияләү максатларында куллану.».

2. Әлеге карарны рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Мордва Афонькәсе авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе А.И.Митяев